**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2075**
**01.04.2024**

Башкарма комитетның 2016 елның 11 ноябрендәге 5925 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешнең 15 пунктчасы, Россия Федерациясе Элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгының «Россия Федерациясе субъектларында вакытлы матбугат басмаларын һәм башка басма продукцияне ваклап сату системасына ярдәм күрсәтү һәм үстерү буенча тәкъдимнәрне раслау турында» 2013 елның 31 июлендәге 197 номерлы Приказының 16 пункты, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2016 елның 11 ноябрендәге 5925 номерлы Карары белән (Башкарма комитетның 2017 елның 17 апрелендәге 2289 номерлы, 2021 елның 29 гыйнварындагы 543 номерлы, 2023 елның 15 маендагы 3927 номерлы, 2023 елның 27 октябрендәге 10342 номерлы Карарлары редакциясендә) расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезләмәгә, түбәндәге эчтәлектәге 22.1 пункт өстәп, үзгәрешләр кертергә:

«22.1. Басма продукция сату буенча стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга шартнамә буенча түләү күләме аена 1 квадрат метр өчен 20 сум күләмендә билгеләнә.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага, Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов